# Лицей сулышы

5 НЧЕ ЛИЦЕЙГА 150 ЕЛ





«5нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Рахматуллина Гүзәл Гаяз кызы

Лицей турында

1872 елда нигезләнә. 2022-2023 нче уку елында 900 укучыга 53 укытучы белем бирә.

«5нче Лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесы - Татарстанда иң өлкән гомуми белем бирү оешмасы. 2022 елның 12 ноябрендә лицейның һәм ул үсеп чыккан 5нче мәктәпнең чишмә башы булып торган Петровский хатын-кызлар училищесына 150 ел тулды.

5нче лицей - 1996, 1997, 1998, 2000, 2001, 2002 елларда Россия күләмендәге «Ел мәктәбе» бәйгесе лауреаты.

2004 елда «Академик мәктәп» исеме бирелә, 2000 елда лицей Россия Федерациясе  мәгариф министрлыгы һәм АКШның Россия Федерациясендәге илчелеге тарафыннан Америка халыкара мәгариф советлары катнашында уздырылган «Мәгарифтә партнерлык» халыкара бәйгесендә җинде, 2006 елда - республика күләмендәге «Матур мәктәп» бәйгесе лауреаты булды. Лицей Казан (Идел буе)

федераль университетының Университет белем бирү округы әъзасы булып тора.

5нче Лицей - «Җәмгыять үсешенең хәзерге этабында гражданлык белеме программасын гамәлгә ашыру» темасы буенча Казан шәһәре мәгариф идарәсенең инновацион мәйданчыгы, «Укучыларның Россия

граждан тәңгәллеген формалаштыру нигезе буларак поликультур белем» федераль экспериментында катнашучы.

Лицейда балаларга белем һәм тәрбия бирү Россиядәге күп еллар яшәп килгән классик мәгариф идеаллары белән бергә заманча мәгарифне гуманлаштыру, мәгълүмати технологияләр, интернациональлек белән баетуга нигезләнеп алып барыла.
5нче лицей - Татарстан Республикасында инглиз теле белән беррәттән поляк теле дә өйрәнелә торган бердәнбер уку йорты. Лицеебызның тагын бер үзенчәлеге шул: ул Татарстан Республикасында поляк телен өйрәтүче бердәнбер мәктәп булып тора. Ул Польша Республикасы мәктәпләре, андагы татар диаспрасы белән дә тыгыз хезмәттәшлек итә. “Ак бөркет” Польша милли мәдәни җәмгыяте чараларында укучылар актив катнашалар. «АК БӨРКЕТ» Польша милли мәдәни җәмгыяте 2015 елның 6 ноябрендә 5 лицейда РФдәге Польша Илчесе Катажина Пелчинская-Наленч җитәкчелегендәге рәсми сайланган затлар булып китте. Алар: Польша Илчелегенең икътисад бүлеге җитәкчесе—Ивона Вишньевска, Илчелектэ матбугат хезмәткәре, сәяси бүлекнец икенче секретаре—Бартош Чихоцки, Мәскәүдәге поляк мәдәнияте үзәгенең директоры - Дариуш Клеховский 5 лицей һәм “Ак бөркет” поляк милли мәдәни җәмгыятенең эше белән таныштылар.

“АК БӨРКЕТ”

Һәр халыкның үз теле, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте. Һәм җиргә туган һәр буын яшәеш табигатенең чишмә башын, үзен яшәтүче тамырларын өйрәнергә тиеш.

Җәмгыятькә нигез салынган:1993 ел.

Рәис вазыйфасына билгеләнгән: Ольга Викторовна Рисположенская. Мактаулы әгъзалары- Волкова Гелнар Фәхриевна—РФнең һәм ТРның атказанган укытучысы, 1993 елдан башлап җәмгыятьнең рәисе, ПРның “Алтын хаҗ” ордены белән бүләкләнгән;

Макарьян Неонила Евгеньевна—филология фәннәре кандидаты, поляк теле укытучысы һәм тел вә әдәбият өйрәнү программасы авторы, ПРның “Алтын хаҗ” ордены белән бүләкләнгән; Сидорова-Ржевутска Мария Владимировна—поляк теленә өйрәтү программасы авторы һәм поляк телен беренче укытучы (2013елда вафат)

Җәмгыять Татарстанда Казан (Идел буе) федераль университеты һәм университет мөхите белән тыгыз мөнәсәбәттә эшли.

Рәсәй Федерациясендә Рәсәйдәге Польша Илчелеге, Мәскәү һәм Петербургтагы Мәскәү йорты, Польшада-Лодзь шәһәре җитәкчелеге, Лодзь шәһәрендәге 19нчы гимназия белән килешү нигезендә һәм Варшава университеты белән тыгыз элемтәдә эшли.

Җәмгыятьнең төп эш юнәлешләре:

1 .Поляк милләтеннән булган балалар белән укыту-тәрбия эшләре, укучыларны Казанда булып кайткан поляклар белән очраштыру;

2.Эзләнүләр алып бару, Арча зиратындагы поляк каберләрен карап- тәрбияләп тору;

3 .Җәмгыять әгъзалары белән поляк халкы тарихын, мәдәниятен өйрәнү, милли бәйрәмнәр үткәрү;

4.Фәнни-практик конференцияләрдә даими катнашу.

Жәмгыять 38 поляк милләтеннән булган әгъзалардан һәм аларга туганлыкта торган затлардан тезелә.

Польшаның күренекле сәясәтчеләре һәм җәмәгать эшлеклеләре—“Ак бөркет”нең кунаклары:

М.Чернявский--Польша Сеймы сенаторы;

В.Цимошевич—1997 елдан ПР җитәкчесенең беренче урынбасары;



Ю.Кашлев—1997 елдан ПРда РФнең илчесе;

Пенчак—1997 елдан Лодзь шәһәре башлыгы;

Л.Миллер—1997 елдан ПРның тышкы эшләр министры;

Ю.Конопацкий—2001 елдан ПРтатарлары Конгрессы рәисе;

Цабан—профессор, 2006 елдан Польша һәм Рәсәй тарихчылары комиссиясе рәисе;

Д.Джал—2009 елдан ПРның РФ дәге Илчелек вәкиле;

А. Жебровска—2009 елдан “Выборча” гэзите(Варшава) журналисты;

Е. Шахуневич—2005,2010,2012 елларда Польша татарлары Шурасының президент урынбасары ;

Р.Солкишек—2005 елдан Гданск шәһәрендә татар мәдәнияте Үзәге директоры ;

Т.Врона—2006 елдан Чанстохова шәһәре башлыгы;

Милота—2006 елдан РФдә Польша Илчелегененд дәүләт киңәшчесе;

М.Гречило—2009 елдан РФдә ПР Илчелегендә Консульлек бүлеге башлыгы ;

Д.Грачик—2006 елдан ПР Илчелегенең РФдәге вәкиле;

Е.Борейша—2009 елдан Польша фәннәр Академиясе профессоры;

МШмая—2010 елдан Лодзь шәһәр җитәкчелеге вәкиле;

П.Марциняк—2010 елдан РФдәге Илче урынбасары;

Заянчьковский—ПРның РФдәге Илчесе (2011ел).

Б.Корпак—2012 елдан Польшадагы студентларның спорт хәрәкәте шурасының рәисе;

А.Бойке—Польша халык телевидениесенең баш хәбәрчесе (2013ел).

Поляк затыннан булган җәмгыять әгъзалары фәнни тикшеренү эшләрендә дә ныклы катнашалар. Н.Е.Макарьян җитәкчелегендәге Республика бәйгеләрендә "Данлы җиңү-хәтерләрдә" (поляк телендә) Мария Макарова , "Туган йортыбыз— Татарстан" К.Цивильская 1урыннарны яуладылар.

Җәмгыять әгъзалары, поляклар җирләнгән каберлекләрне саклау максатыннан, Арча зиратын игътибар Үзәгендә тоталар. Берничә ел элек, без каберлекләрне барлап өлгерүгә, Казанда Костел ачылырга өлгергәнче үк җәмгыятьнең рәисе Г.Ф. Волкова Арча зираты кәшәнәсен тезекләндерү мөмкинлекләрен тапты.

Җәмгыять форум, конференцияләрдә катнашу аша поляк җәмгыятен халыкка таныту белән шөгыльлләнә:

-2006, 2008 елларда Мәскәү һәм Санкт- Петербургта уздырылган яшь поляклар съезды.

-2006 елда -Казан Дәүләт Университеты җирлегендә уздырылган "Бөтендөнья сәяси вә мәдәни киңлеге: тарих һәм заман"исемле халыкара фәнни конференция.

-2007елда Татарстан халыкларының II конгрессы

-2009ел—милли-мәдәни автономияләр конгрессы

-2010ел—"Икенче буын мәгариф калыпларын үзләштерү шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү"дип аталган фәнни-практик конференция шундыйлардан.

Менә инде 20 ел дәвамында 5нче лицей укучылары халыкара "Вспульнота польска"оешмасы һәм

ПРның РФдәге Илчелеге ярдәмендә тел күнекмәләрен Польша Республикасында үтәләр. 2012 елда сайланган балалар Польша Республикасы конгресс чакыруы буенча Гданск шәһәрендә булып кайттылар. 2013 елның җәендә 5нче лицейдан 10 укучы Ворцлав янында V халыкара Польша яшьләре "Полоникус—2013" җыенында катнаштылар. Балаларның тәрбияви дәрәҗәсе, фикерләү вә аралашу сәләтләре оештыручылар тарафыннан югары бәяләнде. Бу—лицей эшенең яхшы күрсәткече.

"Ак бөркет" Польша җәмгыяте Татарстанда яшәүче халыкларга карата җитәкчелекнең игьтибарлылыгы, этник мәдәни һәм милли мәгариф ихтыяҗларын тиешле социаль институтлар аша дәүләти тәэмин итүе өчен чын күңелдән рәхмәт белдерә.

Лицейның эксперименталь эшендә үсеп килүче буынны халыкара мәгариф киңлегенә кертү, дөнья гражданнарын, толерант шәхесләрне, актив гражданлык позициясен формалаштыру максатыннан халыкара хезмәттәшлекне киңәйтү аша «Дөнья гражданины мәктәбе» проектын гамәлгә ашыру мөһим урын алып тора.

**Мәктәбем**

Мәктәбем - зур маяк,
Матурлык, яктылык.
Тора бит күңелем
Гел шунда тартылып.

Мәктәбем – хәзинә
Белемнәр ачкычы,
Дөньяның серләре,
Акылның баскычы.

Мәктәбем – җылылык,
Балачак учагы.
Каршылый ул безне
Киң җәеп кочагын.

Мәктәбем дәверле,
Тарихын син өйрән!
Йөз илле  яшь аңа,
Үткәне бик тирән!

Хатын-кыз мәктәбе
Булган ул кайчандыр.
Сәхифә битләрен
Ул безгә ачадыр!

Госпиталь урнашкан

Сугышлар чорында.

Диварлар хәтерли

Һәр кызын, улын да.

Зур түгел мәктәбем

Нибары өч катлы!

Ә үзе гаҗәеп

Борынгы һәм затлы!

Бик якын ул безгә,

Кадерле, күңелле

Белемнәр бирә дә

Матурлый күңелне!

Шәйдуллина Гүзәлия Хәлим кызы

## ЛИЦЕЙ ХӘБӘРЛӘРЕ

Укучыларны әхлаклы шәхес итеп тәрбияләү максатыннан әхлак дәресләре үткәрелә. Милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне кайтару йөзеннән, һәрдаим ачык чаралар, бәйрәмнәр уздырыла. Бу бәйрәмнәрдә татар укучыларының гына түгел, ә рус балаларының да татарча чыгыш ясаулары безнең өчен зур куаныч.

“5 нче лицейның” укытучылары да, укучылары да район һәм республика күләмендә үткәрелә торган конкурс һәм ярышларда, район күләмендә үткәрелә торган фәнни-практик конференцияләрдә дә актив катнашалар, төрле дәрәҗәдәге бүләкләргә лаек булалар.

Укытучылар бу уңышларга иҗади якын килеп, тырышлык нәтиҗәсендә ирешәләр. Укучыларның белем сыйфаты, аларның олимпиадаларда катнашуы, мәктәпне тәмамлаганнан соң югары уку йортларына керүе – лицейда бирелә торган белемнең гомуми нәтиҗәсен күрсәтә. Шул юнәлештә заман куйган таләпләрне тормышка ашырырга тырышабыз. Мөһим әйберләр турында әңгәмә

5 сентябрьдә бөтен Россия буенча "Мөһим турында сөйләшүләр" дәресләре циклы старт алды!

2022 елның 5 сентябрендә лицейның 1-11 сыйныф укучылары өчен гомуммәктәп линейкасыннан башлана, анда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы флагларын чыгару тантанасы һәм Россия Федерациясе гимны үтәлеше үткәрелә. Аннары укучылар сыйныф кабинетларына «мөһим нәрсә турында сөйләшү»дәресенә китәләр. РФ Мәгариф министрлыгы тәкъдимнәре буенча, яңа уку елында бу тантана һәм патриотик, әхлакый һәм экологик юнәлешле «мөһим турында сөйләшү» информацион - агарту дәресләре атна саен дүшәмбе көнне көн башында үткәрелә.



Бу уку елындагы һәр уку атнасы хәзерге заман балаларын борчыган төрле темаларга багышланган «Мөһим турында сөйләшүләр» сыйныф сәгатеннән башлана. «Мөһим турында сөйләшүләр"нең төп темалары-патриотизм һәм гражданлык тәрбиясе, тарихи тәрбия, әхлак, экология һәм башкалар

Төп темалар бүгенге Россиядә кеше тормышының төп аспектлары белән бәйле. Сәяси эшчәнлек турында һәм теге яки бу эштә уңышларга ирешү турында, сыйныф җитәкчеләре һәм укучылар гаилә гореф-гадәтләре, дәүләт символлары, заманча фән турында сөйләшәләр.

Сыйныфларда, Цифрлаштыру елы кысаларында , “Пилотсыз технологияләр” темасына “Урок цифры” дәресләре уза. Укучылар пилотсыз технологияләр, аларның үсеше, төрле аппаратлар, аларны куллану даирәсе турында мәгълүматлар беләләр.

Янгын куркынычсызлыгына каршы өйрәнү эвакуациясе



Лицейда план нигезендә янгын куркынычсызлыгына каршы өйрәнү эвакуациясе үткәрелде.




Бүгенге көндә Украинада баручы махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләргә укучылар күңел күтәргеч һәм рухландыргыч хатлар яздылар. Аларның сау-сәламәт булып, тиз арада җиңү белән һәрберсенең гаиләләренә әйләнеп кайтуларын теләделәр.



Укучыларның туклануы

Укучыларның туклануы- иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Ата-аналар да туклануны һәрвакыт контрольдә тоталар, меню белән танышалар, ризыкның сыйфатына бәя биреп китәләр.

## ФАЙДАЛЫ ОЧРАШУ



Юл йөрү кагыйдәләрен белү буенча профилактик чара уздыру максатыннан Ганеева Н.Н. белән очрашу үткәрелде. Укучылар белән юл хәрәкәте иминлеге буенча профилактик әңгәмә үткәрде. Шулай ук укучылар «Юл кагыйдәләрен һәркем белергә тиеш» уен-конкурсында катнаштылар.

Конкурс юл хәрәкәте кагыйдәләрен, светофор сигналларын, җәмәгать транспортында һәм юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белүгә багышланган иде.

Укытучылар белән "21 гасыр укучыларын функциональ уку күнекмәләрен формалаштыру" темасына практик дәресләр үткәрелә. Функциональ грамоталылыкны үстерү контекстында дәресләр төзү һәм уздыру буенча методик тәкъдимнәр турында фикер алышалар. Укытучылар тарафыннан уку белемен формалаштыру, үстерү һәм бәяләү өчен биремнәр типлары тәкъдим ителә, дәрес эчтәлегенә кертү өчен биремнәрне сайлап алу чыганаклары тәкъдим ителә.



Баш мөхәррир: Таһирова Гөлназ Гарифулловна.

Рәссам, язмаларны компьютерда җыючы: Гильманова Сабина

Хатлар языгыз:

gulnaz-tagirova@mail.ru

420012, Вахитов районы, Волков урамы, 3

5 нче лицей  ГБМБУ

Телефон: 238-33-60